**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3876**
**12.05.2023**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4571 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2021 елның 8 апрелендәге 2430 номерлы, 2021 елның 7 декабрендәге 7933 номерлы, 2022 елның 2 декабрендәге 6794 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) булдыру турында» 2010 елның 15 гыйнварындагы 6 номерлы карары» сүзләрен «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Карары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 12 маендагы
3876 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2020 елның 14 сентябрендәге
4571 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
гражданнар оборонасы хезмәтләре исемлеге һәм
составы

| № т/б | ГО хезмәтләренең исеме | ГО хезмәтләрен формалаштыручы | Фамилиясе, исеме һәм атасының исеме | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Хезмәт башлыгы | Хезмәт штабы башлыгы |
| 1. | Инженерлык | Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе | Ганиев Айрат Сәйдәш улы | Лотфрахманов Динар Илдар улы |
| 2. | Сәүдә һәм туклану | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге | Солтанова Рәисә Кәүсәр кызы | Зыятдинова Елена Петровна |
| 3. | Медицина | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе | Ногманов Рөстәм Марат улы (килешү буенча) | Борһанова Айгөл Әбүзәр кызы (килешү буенча) |
| 4. | Коммуналь-техник | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Кондрабаева Әлфия Ринат кызы | Мусина Лиана Гали кызы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Җәмәгать тәртибен саклау | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе | Нәҗмиев Раил Радик улы (килешү буенча) | Солтанов Марат Фарасат улы (килешү буенча) |
| 6. | Янгынга каршы | ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Дәүләт янгынга каршы хезмәте федераль янгынга каршы хезмәтенең 15 нче янгын сүндерү-коткару отряды | Мифтахетдинов Алмаз Шәйхенур улы (килешү буенча) | Хәйретдинов Марат Шамил улы (килешү буенча) |
| 7. | Элемтә һәм хәбәр итү | «Таттелеком» ААҖ филиалы – Яр Чаллы зональ электр элемтәсе узелы | Нургалиев Илдар Таһирҗан улы (килешү буенча) | Устинов Андрей Юрьевич (килешү буенча) |
| 8. | Транспорт | Башкарма комитет шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенең транспорт һәм элемтә бүлеге | Парамонов Максим Геннадьевич | Фролов Вячеслав Юрьевич |
| 9. | Ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү | «Татнефть-АЗС Центр» ҖЧҖнең Чаллы филиалы | Хәбибрахманов Рәшит Гыйльфан улы (килешү буенча) | Вдовьев Сергей Владимирович (килешү буенча) |
| 10. | Юл | «Автомобиль юллары предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе | Анисимов Марат Александрович | Хөснетдинов Илнур Рафис улы |
| 11. | Энергетика | «Челтәрләр компаниясе» ААҖ филиалы – Яр Чаллы электр челтәрләре | Шаронов Эдуард Павлович (килешү буенча) | Сәлахов Марат Марс улы (килешү буенча) |
| 12. | Санитар-эпидемиологик күзәтчелек | «Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге» | Бариев Илгизәр Габделхалик улы (килешү буенча) | Ризванов Данияр Әзһәт улы (килешү буенча) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Яр Чаллы шәһәрендәге, Актаныш районындагы филиалы | | |
| 13. | Мәдәни кыйммәтләрне саклау | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | Кәрамиев Румил Рәүф улы | Козлова Лилия Рамил кызы |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева